СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

25 гыйнвар, 1997ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.

№ 9 (8021)

Бәясе билгеләнгәнчә

## Депутатлыкка кандидатлар теркәлде

**Татарстан Республикасы халык депутатын сайлау буенча Октябрь административ - территориаль район комиссиясенең 1997 елның 23 гыйнваренда узган утырышында 50 нче Октябрь админстратив - территориаль сайлау округыннан Татарстан Республикасы халык депутатлыгына кандидат итеп 1950 елда туган, «Норлат шикәр заводы» акционерлык җәмгыяте сайлаучылары җыелышында күрсәтелгән, халык депутатларының Октябрь район Советы рәисе, Октябрь район хакимияте башлыгы ФАТЫЙХ СӘҮБӘН улы СИБАГАТУЛЛИН теркәлде.**

***

**Октябрь район Советына халык депутатларын сайлау буенча район сайлау комиссиясенең 1997 ел, 22 гыйнвар утырышында 18 нче Егоркино сайлау округыннан халык депутатларының Октябрь район Советына депутатлыкка кандидат итеп 1950 елда туган, Кузнецов исемендәге крестьян хуҗалыклары ассоциациясе сайлаучылары җыелышында күрсәтелгән «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең Норлат разведка бораулавы идарәсе начальнигы АНАТОЛИЙ СТЕПАНОВИЧ НАСОЛДИН теркәлде.**

## Районыбыз хәбәрләр тормышыннан

### *Ипине яраттылар*

Тимер юл эшчеләрне тәэмин итү бүлеге икмәк пешерүчеләре соңгы айда сатып алучыларны тагын бер продукция белән сөендерде, ул «Кишинев» икмәге. Яңа ипи төрле сорт он кушып 850 граммлы ипи яки батон рәвешендә пешерелә. Яңа продукцияне сатып алучылар бик тиз үз итеп өлгерделәр, яратып алалар.

Сүз уңаеннан, гыйнвар башыннан икмәк продукцияләре ипи кибетендә генә түгел, ОРСның башка сәүдә нокталары - «Радуга», сөт кибетләрендә дә сатыла башлады. Бу сатып алучыларга тоткарлыксыз хезмәт күрсәтү мөмкинлеге бирә.

### *Кулланучылары күп*

«Сельхозтехника»ның кислород цехы рентабльле эшләүче подразделениеләрнең берсе.

18 кешедән торган коллектив тәүлегенә 120 баллонга кислород тутыра. Ә цехның кулланучылары байтак. Октябрь, Аксубай, Чирмешән районнары гына түгел, Самара, Ульян өлкәсенең безнең белән ызандаш районнары да кислородны биредән сатып алуны хуп күрәләр.

### *Укучыларга - кайнар аш*

Республика Министрлар кабинеты агымдагы елның 16 гыйнваренда мәктәп яшендәге балалары булган, бигрәк тә аз керемле гаиләләрнең мәнфәгатьләренә кагылышлы һәм күптән көтелгән Карар кабул итте. «1997 елда Татарстан Республикасының гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучыларны ашатуны оештыру турында»гы бу карар республика матбугатында дөнья күрде.

Нәкъ менә шул карарны район территориясендә гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләрне тикшерү өчен узган сишәмбе көн район хакимияте башлыгы урынбасары - финанс бүлеге мөдире Р.Г.Билалов киңәшмә уздырды. Анда шәһәр мәктәпләре директорлары, мәктәпкәчә учреждениеләр мөдирләре, районның социаль яклау службасы һәм финанс бүлегенең җаваплы хезмәткәрләре катнашты. Киңәшмәдә әлеге карарны гамәлгә ашыруга карата конкрет мәсьәләләр каралды. Балаларның кайнар ашын оештыру турында җентекләбрәк махсус хәбәр ителәчәк.

## *Хезмәтләре белән мактаулылар*



«Чирмешән» крестьян хуҗалыклары ассоциациясенең соңгы елларда терлекчелек өлкәсендәге уңышлары сизелерлек. Бүген дә биредә сыерлардан көнлек савым 8,3 килограмм тәшкил итә, бу - узган ел белән чагыштырганда 500 граммга артыграк.

Хуҗалыкның бу уңышында сыер савучы Роза Гатинаның да өлеше бар. Урта мәктәпне тәмамлауга терлекчелеккә эшкә килгән Роза - хәзер ике бала анасы, тәҗрибәле савучы булып җитеште. Узган ел ул беренче кат бозаулаган таналар группасында эшләде, һәр малдан 3293әр килограмм сөт савып алды. Розаның тырышлыгы, хезмәт·сөючәнлеге нәтиҗәсендә мөмкин булды бу күрсәткеч. Савучы яңа елны да шундый ук күтәренкелек, тырышлык белән башлап җибәрде, исәбе - узган елгы үрдән чикмәскә.

**Рәсемдә: Р.Гатина. Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## *КҮЗЕБЕЗ - ГАЗҮТКӘРГЕЧТӘ*

«Әле кайчан гына Западный микрорайонында (Әфган поселогы) нибары берничә йорт булган булса, соңгы ике - өч елда алар яңгырдан соң чыккан гөмбә кебек берсе артынан берсе калкып кына тора. Инде тулы бер урамнар хасил булды (дөрес, алар әлегә исемсез). Мәгълүм ки, биредә нигездә яшь гаиләләр яши, күбесенең мәктәп яшендәге яки кечкенә балалары бар. Тик менә яшәү шартларыбыз һич тә мактанырлык түгел шул: ни суы, ни юлы, ни җылысы юк.

Шуңа күрә без, бу микрорайонда яшәүчеләр безнең йортларга табигый газ китерүне тизләтүләрен сорар идек. Җитмәсә газүткәргеч тә безнең поселок аркылы уза бит. Ә инде бездән торганын эшләргә - тиешле акчаны күчерергә без бүгеннән әзер - эше генә эшләнсен иде.

**Микрорайон халкы.**

**РЕДАКЦИЯДӘН:** Күп кеше имза куйган менә шундый хат алдык. Хат авторлары аңа җитәкчеләрнең газета аркылы җавап бирүләрен сорыйлар.

Аларның үтенечено колак салып, без шәһәр җирле үзидарә Советы рәисе Ф.И.Гайнуллин белән телефон аша элемтәгә кердек. Ул менә нәрсә диде:

« Хәзерге вакытта әлеге микрорайонда юллар, суүткәргеч һәм канализация челтәре төзү буенча проект документлары эшләү тәгәлләнә. Газны да проектлау эшләре башланган - түзсеннәр инде бераз. Ә урамнарга исем бирү мәсьәләсенә килгәндә, шәһәр Советының тиешле службалары ул эшне февральдә башкарачаклар».

## Пенсияләрне вакытында түләргә

Татарстан Министрлар Кабинеты пенсияләрне вакытында түләүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын билгеләде. Хакимият органнарына, республика оешмаларына тиешле йөкләмәләр бирелде. Аерым алганда, Пенсия фондының республика бүлегенә пенсияләрне шәһәр һәм районнардан кергән иминият кертемнәренә пропорциональ рәвештә түләргә тәкъдим ителде. Шәһәр һәм район хакимиятләренә Пенсия фондына акчаның вакытында һәм тулысынча керүен тәэмин итү өчен кирәкле чаралар күрергә кушылды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 20 гыйнварда кабул ителгән «Пенсияләрне вакытында түләүне тәэмин итүнең кичектергесез чаралары турында»гы карарында шушы һәм башка чаралар турында әйтелә.

**Татарстан республикасы хөкүмәте матбугат үзәге.**

## Кем тиз тоткан - шул откан, кем пошмаган ... ыргыткан

Районда терлекчелек тармагында эшне фән һәм алдынгы тәҗрибә кушканча оештыру, тиз арада җайга салу буенча зур чаралары күрелә. Сөт терлекчелегенә килгәндә, бүген төп бурыч савым көтүен ашату һәм карау технологиясе таләпләрен төгәл үтәүгә ирешү, сыерларны бозаулатуга җиренә җиткереп әзерләп алардан сәламәт үрчем алу, туган бозауларны исән - сау саклап үстереп, бүген савымны арттыруга ирешү һәм киләчәктә көтүне мул продукт бирергә сәләтле таналар белән тулыландыруга нигез булдырудан гыйбарәт. Нәкъ менә шул максаттан сөт ташлаткан сыерларны махсус рацион белән ашату, алардан алынган үрчемне салкында асрау кебек ышанычлы һәм нәтиҗәле ысулны кыю куллану зарурлыгы турында һәрдаим сүз бара, хуҗалык җитәкчеләрен бу юнәлештә нәтиҗәле эшләп сөт җитештерүдә бик нык алга киткән районнарга алып барып кайту да шул нияттән оештырылган иде. Бу эшкә җитди караган хуҗалыкларда яңалыкның отышлы булуын вакытында аңлап аны шунда ук үзләрендә кертә башладылар. Бу уңайдан «Чирмешән», «Кондырча», «Мамык», Муса Җәлил исемендәге һәм кайбер башка ассоциацияләрне уңай яктан гына телгә алырга була. Хәзер «Үрнәк» хуҗалыгы белән кушылган элеккеге «Путь к коммунизму» сыер фермасында да эшне шулай оештыруга җитди карадылар. Аларда бозаулату алды бүлегендәге сыерларның рационына икешәр килограмм пешерелгән солы өстәлә һәм бу малларның физиологик торышында үзен шунда ук сиздерде. Һәм билгеле инде, көр малдан туган бозау да ни җитте генә булмый. Өстәвенә, югарыда телгә алынган хуҗалыкларда бозаулату бүлекләрендә махсус терлекчеләрнең дежурлыгы оештырылып, аларның малларны һәрдаим игътибар үзәгендә тотуы, яңа туган бозауларга да тиешле игътибар күрсәтүе, аерым алганда, аларга утыз сөтен эчертү, аннан соң да көнгә өч тапкыр җылытылган сөтне туйганчы эчертү нәтиҗәсез калмый - бозауларның саклануына күз генә тимәсен.

Ә менә бозауларны салкында асрау эшен оештыруга бармак аша гына карган хуҗалыкларда хәл бөтенләй башкача. Әйтик, «Правда» ассоциациясендә былтыр 99, «Сөлчә» һәм «Игенче»дә 91 - 92 яшь бозау үлде. Һәм моннан тиешле нәтиҗә ясалды дип уйлыйсызмы? Һич юк. Ул хуҗалыкларның икесендә бозауларны салкында асрауга күчү турында уйлап та карамыйлар, өченчесендә дә ул эш җиренә җиткерелмәгән - терлекчеләрнең дежурлыгы оештырылмаган.

Җиренә җиткерү дигәннән, «Комбайн» ассоциациясендә дә бу мәсьәләгә мөнәсәбәт аңлашылмый: «салкын» читлекләрне тиешле дезинфекияләү уздырылмаган элеккеге абзар эченә урнаштырганнар, ә тыштагы читлекләр буш тора. Ул җәһәттән «Төрнәс»тә дә «салкын» читлекләр була торып аларга бозауларны күчерергә ашыкмыйлар. Кузнецов исемендәге хуҗалыкның Егоркино бригадасында да салкында асрау ысулын санга сугарга теләмиләр төсле. Мөгаен, яшь үрчемнең тагын бер тапкыр массовый кырылуын көтә торганнардыр.

Югыйсә бит бу алымны санга сукмауның ачы тәҗрибәсен үз җилкәләрендә татыган хуҗалыклар тагын да бар. Әнә «Рассвет»та бу эшкә тотынырга башта бик ашыкмаганнар иде. Ә җавапсызлык, бигрәк тә ветеринария хезмәткәрләренең игътибарсызлыгы үзен бик тиз сиздерде - яшь бозаулар арасында колибактериоз инфекциясе таралды. Соңга калып булса да бозауларны салкында асрауга күчкәч хәл уңайга китте китүен, әмма аңа кадәр никадәр яшь үрчемне тиреслеккә чыгарып ташларга туры килүен дә онытмыйк.

Шуңа күрә савым көтүен карау технологиясенең бозауларны салкында асрау кебек мөһим элементын һич тә уенга алырга ярамый. Һәр хуҗалыкта йөз сыерга кимендә 14 - 15 исәбеннән «салкын» читлек ясатып, бозауларны шунда асрауның барлык таләпләрен җиренә җиткереп башкару шарт. Бераз мәшәкатьлерәк эш булса да, әҗерен барыбер кайтарачак ул, алга таба савым көтүен мул продуктлы итү өчен ышанычлы бер нигез булачак.

***Акцияләр сатып алабыз***

**«Татнефть» АҖнең Б категорияле,**
**«Сургутнефтегаз» АҖ,**
**«ЛУКойл НК» АҖ,**
**«ЛУКойл - Лангепаснефтегаз» АҖ,**
**«ЛУКойл - Урайнефтегаз» АҖ,**
**«ЛУКойл - Когалымнефтегаз» АҖ,**
**«Ноябрьскнефтегаз» АҖ,**
**«Газпром» РАҖ акцияләрен.**

Безнең адрес: «Сервистехинвест» ЧИФ. К.Маркс ур., 12 (ишеге яннан). Тел.: 2 - 19 -30.

## *Котлыйбыз*

*Тимер юл транспорты өлкәсендә озак еллар нәтиҗәле эшләгән өчен Куйбышев тимер юлының Ульяновск бүлекчәсе Норлат тимер юл станциясе начальнигы **Любовь Никифоровна ГАЗИЗУЛЛИНА** Татарстан Республикасының Мактау Грамотасы белән бүләкләнде.*

Шәхси хуҗалык - өстәмә чыганак

# ОЕШТЫРЫРГА ГЫНА КИРӘК

Быелтыр Егоркино җирле үзидарәсе территориясендә шәхси хуҗалыклардагы сыер башына 231 килограмм сөт җыелды. Быел район буенча ул күрсәткечне 445 килограммга җиткерү бурычы куелды. Моңа ирешү өчен реаль мөмкинлекләр бар. Шул исәптәнКузнецов исемендәге ассоциациядә дә.

- Совет территориясендәге дүрт авылда 569 крестьян хуҗалыгы булып, аларда 348 сыер асрала,-ди Совет рәисе урынбсары Зоя Филипповна Терентьева. - Аларның иң күбе - 201е Егоркинода, Каравыл Тавында бу сан икеләтә кимрәк, Рус Мәнҗесендә 24, нигездә пенсионерлар яши торган Единение поселогында 14 сыер тотыла.

Сөт җыю белән ике кеше - Н.Малейкин һәм Т.Шерникова шөгыльләнәләр. Аларга булышчылар өстәлсә дә начар булмас иде, өстәвенә, Каравыл Тавында сөт җыю эше яхшыртуны сорый.

Дөрес, эшне уйлап оештырганда, вакытында түләп барганда халык үзләреннән арткан сөтне сатарга каршы түгел. Ни әйтсәң дә, айлар буе хезмәт хакы күрмәгәндә сөт акчасы берәүнең дә кесәсен тишми анысы. Әйтик, узган ел терлекче И.Яллин гаиләсе бер айда гына да 244 мең сумлык, мастерской мөдире Ю.Ендиряков 376 мең сумлык сөт тапшырды. Пенсионерлар И.Киргизов,В.Яллин, О.Перепелкина, электрик В.Михеев та сөт тапшыруда активлар. Сөт - `май комбинаты да соңгы вакытта акчаны тоткарлыксыз күчереп бара.Аннары, элекке еллардагыча, җирле ассоциация җитәкчелеге сөт тапшыручыларга продукция күләменә карап печән бирсә дә начар булмас иде. Былтыр әнә ул эшләнмәде һәм бу халыкның активлыгында бик тиз чагылыш тапты. Моннан тыш, сөт җыючылар сөт үлчәгечләр булмаудан да зарланалар - шунсыз төгәл учет алып бару кыен.

Сөт җыю эшен ел дәвамында оештырырга кирәк. Хәзер, кышын сөт аз дип җәйгә генә өметләнергә ярамый. Ә җыелган продукцияне озату проблема түгел.

**Т.АЛЕКСЕЕВА.**

## «Минем Татарстаным» - иншаларда

Туган җир. Ватан. Аның тарихына, иксез - чиксез байлыкларына дан җырлаучы күпме искиткеч һәм ягымлы сүзләр язылган. Бер уйласаң, моңа өстәрлек бернәрсә дә юк кебек. Әмма... Ватан турында сүз чыкканда күңелеңдә аерым, йөрәгеңә якын сүзләр табу белән кызыклы да кеше. Районыбыз укучылары «Минем Татарстаным» дип аталган республика конкурсына иншалар язганда бу аеруча күзгә бәрелә торды. Шәһәрнең беренче һәм дүртенче мәктәпләреннән 5әр, Чулпан урта мәктәбеннән 3, Елаур, Салдакай, Аксумла урта мәктәпләреннән икешәр эш тапшырылды. Шулай ук яңа Әмзә, Биляр Озеро, Гәйтән, Мамык һәм башка мәктәпләрдән дә конкурска кызыклы эшләр китерелде. Шуңа да укучыларның барлык материаллары белән җентекләп таныштык без. Ә иң яхшылары итеп шәһәрнең беренче урта мәктәбеннән унберенче класс укучысы Ю.Пимуллина (укытучысы Л.И.Сидоренко), дүртенче мәктәпнең алтынчы классыннан Т.Сәлахова (укытучысы В.М.Кашкаров) эшләре танылды. Мамык урта мәктәбеннән О.Кузьминаның (укытучысы Т.Н.Фәткуллина) лирик иншасы да югары бәяләнде.

Гомумән, укучыларда туган җирләре, үз халыклары тарихына чиксез мәхәббәт, үз халыкларының кичәгесе һәм бүгенге көне белән горурлану хисенең көчле булуы сокланырлык. Бу инде аларның педагогларының бу юнәлештә максатчан эш алып барулары нәтиҗәсе. Һәм яшь вакытта ук балалар күңелендә кабынган очкын еллар үтү белән тагын да көчлерәк дөрләп, башка йөрәкләрне яндырыр дип ышанасы килә.

**Н.ЗАКИРОВА.**

**район мәгариф бүлеге методисты.**



Миния Вазыйх кызы Абдуллина тимер юл эшчеләрне тәэмин итү бүлегендә 9 еллап эшли. Ул - сатучы, «Радуга» кибете - аның даими эш урыны. Ачык, мөлаем йөзле Миния сатып алучылар өчен күптәннән үз кеше инде. Соңгы елларда кибеткә зур конкуренция булып базар, коммерция киосклары күпләп үсеп чыкса да, тимер юлчыларның бу кибетләреннән сатып алучылар өзелми. Шуңа да Миния кулы аша һәркөнне күпләп азык - төлек продукциясе уза, үзе ничәмә - ничә клиентка хезмәт күрсәтә. Һәм һәрберсе аның итәгатьле мөнәсәбәтеннән, ипле холкыннан, ачык чыраеннан, культуралы хезмәт күрсәтүеннән канәгать калалар.

**Рәсемдә: сатучы М.В.Абдуллина.**

*Тирәбездә яхшы кешеләр*

# *Күңел җылысы белән дә дәвалый*

Талант дигән ходай бирмеше һәркемгә дә бирелгән була, диләр. Тик аны вакытында тоеп - сизеп, үстерә, белем һәм тормыш тәҗрибәсе белән ныгыта белергә генә кирәк. Аннан инде - талантыңны, сәләтеңне кешеләргә хезмәткә багышлыйсы кала...



Валентина Павловна Клементьеваның да тормышында шулай булды. Казан дәүләт медицина институтын тәмамлаганнан соң менә чирек гасырдан артык инде ул Иске Чаллы участок шифаханәсендә эшли. Башта табиб кына иде, аннан терапия бүлеге мөдире булды. Һәм ул еллар эчендә аңа ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән, ул иң авыр минутларында профессиональ белеме белән дә, игътибарлылыгы һәм ягымлы мөгамәләсе белән дә сырхауларын җиңеләйткән, савыктырган кешеләрне бернинди компьютер да санап чыгара алмастыр. Табиб иң элек авыруның хәленә керә белергә, аның хәсрәтен үзенекедәй кабул итә алырга тиеш, дип саный Валентина Павловна. Башкача һич мөмкин түгел, чөнки чиренә үзе генә каршы тора алмаган пациент табибтан ничек дәвалану турында күрсәтмә алырга гына түгел, ә аның савыгуга өметләндерә торган күңел җылысын да тоярга тиеш.

Табибның эше, бигрәк тә авыл җирендә җиңел түгел. Ул эшне, укып башлап та кызыксыз тоелган китап кебек читкә алып куеп тора алмыйсың. Авыруына кайчак йортыңны - гаиләңне дә онытырга, үзеңнең мең төрле мәшәкатьләреңне дә читкә куеп торырга мәҗбүр итә. Син нинди генә хәлдә дә сырхауларга ярдәмгә килергә әзер булып торырга тиешсең. Ул яктан бу участоктагы табибларга эш житәрлек: шифаханә генә дә алтмыш урынлык, тагын профилакторий, жиде фельдшер - акушерлык һәм фельдшерлык пункты бар, биш мең ярымнан артык кеше яши. Һәм Валентна Павловна Чаллы участогындагы пациентларның һәркайсын танып белә. Аның күз алдында инде яңа буыннар үсеп җитте. Әмма пациентлар Валентина Павловнаның йомшак күңелле, игътибарлы булуын әйтәләр, ире Аркадий Леонтьевич кебек үк терапевт Клементьеваны да «безнең доктор» дип йөртәләр.Шушы гомер буена иренең ныклы һәм ышанычлы терәге, авыр минутларда якын киңәшчесе булды ул. Ә хатын - кыз өчен моның никадәр әһәмиятле икәнлеген ул үзе генә белә.

... Иске Чаллы участок шифаханәсенең дәвалау корпусы артында бер җыйнак кына каралты тора. Беренче карашка авылдагы башка йортлардан әллә ни аермасы да юк аның. Тик йорт тирәсендә җәй башыннан көзгә кадәр гөлләр чәчәк атып утыра. Һәм бу йортта гомер кичерүче гаиләдә татулык хөкем сөрүен дә белә авыл халкы. Ә бу шимбәдә дуслары һәм коллегалары бергә бәйрәмгә җыелачаклар. Валентина Павловнаның туган көне. Ничә яшь дисезме? Кем инде хатын - кызның яше белән кызыксына? Иң мөһиме -аның элеккечә үк йомшак күңеле һаман да яшь.

**Т.НАЗАРОВА.**

**Рәсемдә: авыруларны Татарстан Республикасының атказанган врачы В.П.Клементьева кабул итә (уңнан икенче.)**

# ЗАГС: көн туса эш чыгып тора

***ЗАГС бүлеге. Бу учреждениенең эше белән шәһәр халкының куанычлы да, кайгылы да вакыйгалары бәйләнгән. Шулай, 1996 елда 332 кешенең дөньяга килүе, 170 өйләнешү, 98 ае-рылышу, 319 үлем факты теркәлгән. Тик болар һәммәсе дә четрекле көндәлек эшнең бер өлеше генә. Учреждение эшчәнлегенең төп юнәлешләре турында әңгәмәбездә ЗАГС бүлеге мөдире Алевтина Якволевна Матросова сөйли.***

**- Тагын нинди эшләр белән шөгыльләнергә туры килә сезгә?**

- Без ай саен авыл администрацияләре буенча гражданлык хәле турындагы актларны гомумиләштерәбез. Шуны искә төшерәсем килә: гражданлык хәле турындагы актларны теркәүнең үз вакыты бар. Мәсәлән, бала туу вакыйгасы бер ай вакыт эчендә, үлем өч көн дәвамында рәсмиләштерелергә тиеш. Өйләнешү турында документлар өйләнешүне теркәүгә кадәр бер ай алдан икеяклы килешү буенча, аерылышу турында гариза шулай ук бер ай алдан бирелә. Бу срокны киметү яки арттыру закон белән каралмаган. ЗАГС бүлеге граждаң-нарның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аталык яки аналык хокукы билгеләүне, срогын төшереп калдырып яшь билгеләү мәсьәләләрен хәл итә. Шулай ук элеккеге гражданлык хәлләрен теркәгәндә киткән хаталарны төзәтү турында гаризалар кабул итәбез - барлык төрдәге теркәлгән актларга яңабаштан таныклыклар бирәбез. Ел агымында яңабаштан 17 туу турында таныклык, 16 өйләнешү турында, 33 үлем турында таныклыклар бирелде. Район халкының документларга карата сак карашта торуларын телисе килә, чөнки аны яңадан ясату 37.950 сумга төшәчәк.

**- Бүлек нинди тәртиптә эшли?**

- Дүшәмбе һәм сишәмбе көннәрендә без халыкны бөтен мәсьәләләр буенча кабул итәбез, чәршәмбе көнне - аерылышу, пәнҗешәмбе - туу турында таныклык бирәбез, җомга көнне өйләнешүчеләрне теркибез. Туй тантаналарын шимбәгә, якшәмбе һәм бәйрәм көннәрендә үткәрергә теләгән парларга да каршы килмибез.

**- Өйләнешүчеләрнең яшьләре нинди хәзер?**

- Соңгы вакытта 21 - 25 яшьтә һәм аннан да олыраклар арасында рәсми рәвештә кушылуларын теркәүчеләр бик сирәк очрый. Күбрәк 16 - 20 яшьлекләр өйләнешә. Аерым сәбәпләр аркасында безгә өйләнешү яшен кечерәйтергә дә туры килгәли. 1996 елда бер кыз 15 яшьтә,20 кыз 16 - 17дә кияүгә чыктылар. Кызганычка каршы, мондый кушылулар нык булмый: шундый 21 гаиләнең инде 4се таркалды да.

**- Ата - аналар балаларына нинди исемнәр кушалар?**

- Рус кызларында Анастасия, Екатерина, Кристина, Анна, малайларда - Денис, Максим, Дмитрий исемнәре еш очрый. Татар кызлары - Айгөл, Ләйсән, Алия, Әлинә, малайлар - Илнур, Илнар, Руслан, Динар исемнәренә ия булалар. Ата - анасы төрле милләт кешеләре булган гаиләләр балаларын Диана,. Регина, Анжела, Артур, Алиса, Карина, Альберт, Альфред, Эдуард кебек чит ил исемнәре белән атыйлар. Безнең бүлектә татар, рус исемнәре турында махсус белешмәләр бар. Алардан исемнең ни рәвешле кешенең холкына, язмышына йогынты ясавы, балага кайсы айда яки көндә туына карап ниндиерәк исем кушу отышлы һәм башка шундый мәсьәләләрне белергә мөмкин. Килегез, без һәркемгә ярдәм итәргә әзербез.

## «Заман егетләре» - Норлатта



5 февральдә район мәдәният йорты сәхнәсендә популяр «Заман егетләре» ансамбле концерты булачак.

***Ансамбльнең иҗат юлы турында безгә аның администраторы Миләүшә Газизова сөйли.***

**- Ансамбль кайчан профессиональ эстрадага килә?**

- Бу өч ел элек була. Нульдән башлаган ансамбль бүген уңышка да, тыңлаучылар мәхәббәтенә дә, компакт - дисклар чыгаруга да ирешә. Хәзер аларның үз студияләре бар, егетләр анда үз җырларын яздыралар. Алар бик күп эшлиләр, иҗатта шунсыз мөмкин түгел.

**- Бүген аларның иҗади багажыниләрдән гыйбарәт?**

- Группа репертуарында татар халык җырлары күп. Егетләр аны эшкәртеп, үз аранжировкаларында башкаралар. Шулай итеп, җыр яңадан тугандай яңа төсмер, яңа яңгыраш ала. Егетләр репертуарында эстрада җырлары да байтак. Шуңлыктан безнең концертларга төрле буын тамашачылар йөриләр.

**- Миләүшә, «Заман егетләре»нең концерт эшчәнлеге турында җентекләбрәк сөйләсәгез икән.**

- Коллективта 4 башкаручы, әйдәп баручы солистлар - Закир Шаһбан һәм Айрат Гомәров. Алар Татарстан, Оренбург, Урал, Удмуртия, Төмән, Мәскәү шәһәрләрендә гастрольләрдә булалар. 1995 елда алар ил хөкүмәте чакыруы буенча Австриядә булып 7 концерт бирделәр. Узган елның 7 декабрендә «Космос» кунакханәләр комплексының концерт залында Швециядә яздырылган икенче лазер компакт - дискын презентацияләү уңышлы үтте. Мәскәүлеләр егетләрне җылы кабул иттеләр, концерттан соң грим бүлмәсе чәчәкләр, шампан шәрабе һәм сувенирлар белән тулы иде.

Якын көннәрдә алар Чистайда, Яңа Чишмәдә чыгыш ясаячаклар, аннан - Оренбургка һәм мәдәният департаменты чакыруы буенча Свердловскига китәчәкләр. Биредә, җыр сөюче, әйбәт музыканы бәяли белүче Норлатта да безнең группа үз тыңлаучыларын табар дип уйлыйбыз.

**Әңгәмәдәш - Т.НАЗАРОВА.**

## Газета - *укучы* - газета

## Шәфкать ияләренә

Чирне беркем дә күтәп алмый, аның ничек, кайсы яктан килеп аяктан егасын да беркем белми. Әгәр дә ул иң кадерле, иң якын кешенә килсә, кайгың чиксез, әлбәттә. Безнең гаиләбездә нәкъ шундый хәл килеп чыкты: оныгым Павликның авыруы җитди иде. Иң кыен чакта, менә ике тапкыр инде без район үзәк шифаханәсенә мөрәҗәгать иттек. Шәфкатьле, миһербанлы күңелле, шифалы куллы табиблар һәм шәфкать туташлары тәүлекләр буена оныгыбызның сәламәтлеге сагында тордылар. Менә аларның исемнәре: С.Ш.Бикметова - район үзәк шифаханәсенең балалар бүлеге мөдире, Р.Х.Юнысова - поликлиникада балалар табибы, Ф.Ф.Саттарова - дәвалаучы табиб, Ф.И.Талмагамбетова һәм Г.И.Максимова - шәфкать туташлары, Ф.Х.Кәлимуллина - физкабинет шәфкать туташы. Якты йөзле, изге күңелле бу кешеләргә без олы рәхмәтебезне белдерәбез.

**Е. ИВАНИЦКАЯ.**
**Норлат шәһәре.**

Сорау - җавап

## Льготалар каралган

*«Инвалид бала караучы ата - аналарга керем салымы салынганда льготалар каралган дип укыган идек. Ул льготалар нидән гыйбарәт?»*

**Бу сорауга җавапны район салым инспекциясенең физик шәхесләргә салым салу бүлеге начальнигы Тамара Степановна Муракаева бирде.**

- Россия Федерациясенең 1991 елның 7 нче декабрендә «Физик затларга керем салымы салу турында»гы законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән чыккан Законы нигезендә даими тәрбияләүне тәэмин итүче балачактан инвалид яки 1 группа инвалид баласы булган ата - ананың берсенә (алар сайлаганча), ире яки хатыны һәм башка, тәрбия итүче кешегә түбәндәге льгота каралган:

Салым салына торган чорда алынган барлык керем суммасы закон нигезендә билгеләнгән айлык өч минималь хезмәт хакыннан арттырылмаган керем суммасына кадәр киметелә.

Льгота пенсия таныклыгы, тәрбия итүчеләр белән шөгыльләнүче орган карары, сәламәтлек саклау органнарыннан, даими тәрбиягә мохтаҗлыкны раслаучы медицина белешмәсе, бергә яшәү турында торак органнарының белешмәсе нигезендә гамәлгә ашырыла.

## Җирдән файдалану түләүле

Район дәүләт салым инспекциясе җир участоклары булган кешеләрне Татарстан Республикасында җирдән файдалану түләүле икәнлеге турында искәртә. Җиргә хуҗа булучыларга ел саен җир салымы салына. Аның суммасы җир хуҗасының ул участокта хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләренә бәйле. Салым икегә бүлеп сентябрьнең 15нән һәм ноябрьнең 15нән дә калмыйча түләнә. Вакытында түләмәгән очракта һәр сузылган көн өен 0,2 процент зурлыгында пеня ясала. Бакчачылык ширкәтләрендәге участоклар өчен җир салымы түләмәүчеләр бар. Алар нигездә җир участогы алынган оешмадан эштән киткән яки участогын саткан кешеләр. Шуңа күрә андыйлар дәүләт салым инспекциясенә учетка басарга һәм 1995 - 1996 еллар өчен салым түләргә тиешләр. Түләмәүчеләр булуы ачыклангаңда, материаллар салым полициясенә тапшырылачак. Шунысын да әйтик, участокны бүләк итеп яки мирас итеп калдырганда да нотариаль контора дәүләт салым инспекциясеннән белешмә таләп итәчәк, шулай булгач салымын да, пенясын да барыбер түләргә туры киләчәк.

## КОТЛЫЙБЫЗ!



Чишмә авылында яшәүче кадерле әниебез **Нәкыя Хәсән кызы Хәсәншинаны** 55 яше белән котлыйбыз.

Сәламәт бул, гел шат яшә,
Бәхет кунсын күңелең түренә.
Барыбызга канат, терәк булып,
Армый атла гомер түренә.

**Кызларың, кияүләрең, оныкларың.**

## Реклама
## *Белдерүләр*


### *Шәхси фатирын булдырырга теләүчеләр игътибарына!*

***Октябрь хуҗалыкара төзелеш оешмасы администрациясе сезне торак йортлар төзелешенә үз өлешегез белән катнашырга чакыра .***

***Беренчел взнос фатир бәясенең яртысы күләмендә кертелә,* тулы исәп - хисап төзелеш тәмамланганнан соң төзелеш материаллары бәясенең инфляциягә бәйле рәвештә үзгәрүеннән чыгып ясала. Йортлар СПТУ бистәсендә салына.**

**Гомуми мәйданның бер квадрат метры 1 миллион 200 меңнән 1 миллион 400 мең сумга кадәр.**

**Моннан тыш, килешү бәясе буенча СПТУ һәм Төзүчеләр бистәләрендә 6 - 8 сутый участогы белән тәмамланып бетмәгән икешәр фатирлы йортлар да тәкъдим итәбез.**

**Шулай ук әзер проект буенча үзебезнең һәм күрше районнарның теләсә кайсы урынында бер яки ике фатирлы теләсә нинди зурлыктагы йортлар салуга да заявкалар алабыз.**

**Нигез кору, стена өю, отделка һәм ремонт эшләре дә башкарабыз, дача йортлары һәм гаражлар салабыз. Бәясе - килешү буенча.**

**Төзелеш тизләтелгән темпта бара. Эшне вакытында һәм сыйфатлы башкарып чыгу гарантияләнә.**

***Сезне Норлатта Завод ур., 1 адресы буенча МСОда көтәбез, тел.: 2 - 12 - 61.***

Самара өлкәсе Чаллы Башы районының 116 нчы аптекасы Норлат халкына «Октябрь Сельхозтехникасы» АҖнең сәламәтлек пункты бинасында аптека киоскысы ачылу турында хәбәр итә.

А-96 сер. 038625 номерлы лицензия Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы дарулар белән тәэмин итү лицензия комиссиясе тарафыннан бирелгән.

Рөхсәт ителгән эшчәнлек төрләре : дару һәм гигиена араларын ваклап сату.

### Сатабыз



**ЛУАЗ - 969, кыйммәт түгел.** Адрес: Нефтьчеләр ур., 4 - 16, тел.: 5 - 25 - 93 яки 65 - 5 - 64.

***

**1988 елгы ВАЗ - 2105.** Тел. 2 - 26 - 10.

***

Хөрмәтле сатып алучылар!

«777» кибете киң ассортиментта һәм иң арзан бәяләрдә кер юу порошоклары, шампуньнар, сабын һәм башка товарлар тәкъдим итә. Безнең адрес: К.Маркс ур. 27.

***

Октябрь хуҗалыкара төзелеш оешмасы Каравыл Тавы кирпеч заводыннан меңданәсенең бәясен 660 мең сумнан кызыл кирпеч сата. Теләүчеләргә транспорт чыгымнарын түләү шарты белән район эчендә илтеп тә биреп була. Тел.: 2 - 12 - 61.

***

1. Без сезгә организмны чистарту һәм матдәләр алмашын баланслау өчен хәлегездән килерлек бәяләрдә туклану продуктлары тәкъдим итәбез. Тел.: 5 -26 - 61 (сәгать 10 нан 12гә кадәр), 5 - 21 - 27, 2 - 18 - 16 ( кичке сәгать 5 тән 9 га кадәр).

2. Ирләр һәм хатын - кызлар өчен якыннарыгызга бик яхшы бүләк булырлык уникаль француз парфюмериясе һәм косметикасына заказлар кабул итәбез.


Октябрь юл ремонтлау - төзү идарәсе коллективы **әнисе вафат булу сәбәпле** шофер Хәмәткәрим Исмәгыйль улы Алиевның авыр кайгысын уртаклаша.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**





*Бикүле авылында яшәүче* ***әтиебез Хәбибулла һәм әниебез Минсара Садыйковларны 30 еллык юбилейлары*** *белән котлыйбыз. Аларга алдагы көннәрендә дә тигез, матур тормыш, озын гомер телибез.*

***Кияүләре Рөстәм, кызлары Раушания, оныклары Диана.***

## Укучыларыбыз иҗаты

**Роза МӘСЛАХОВА**

### *Балан чәчкә ата*

Балан чәчкә ата акрын гына,
Сихрилеге таңнар калырлык,
Илаһилык, пакьлык, сабырлыгы
Күңелләргә алып салырлык.

Балан чәчкә ата тыныч кына,
Шомырт кебек сипми исләрен,
Тик карасаң аңа, әсир итәр,
Аңларсың син аның хисләрен.

Балан чәчкә ата гүзәл итеп,
Әйтерсең лә сылу кыз бала,
Назлы итеп керфекләрен кага,
Сабыр гына аннан моң ага.

Балан чәчкә ата серле итеп,
Лаләләрдәй янмый ут төсле.
Балан чәчкәсенең әллә шуңа
Матурлыкта ахры, чын көче.


**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2047 данә. Заказ N 5146.

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе.